# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 24 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә “һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 11 статьяның 3 пунктында “яисә” сүзеннән соң “Татарстан Республикасының” сүзләрен өстәргә;

3) 12 статьяда:
а) 1 өлешнең 6 һәм 7 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“6) бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу фактлары буенча мөстәкыйль рәвештә яисә Татарстан Республикасының компетентлы дәүләт органнары, вазыйфаи затлар белән берлектә Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвештәге һәм милек рәвешендәге оешмалар һәм аларның вазыйфаи затлары эшчәнлегенә тикшерү үткәрергә;
7) ачыкланырга тиешле хәлләргә тикшерү үткәрүдә булышлык күрсәтүне сорап, компетентлы дәүләт органнарына, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарына яисә вазыйфаи затларга мөрәҗәгать итәргә;”;

б) 2 пунктның 2 өлешендә “түләүсез” сүзен “түләүсез һәм тоткарлыксыз” сүзләренә алмаштырырга;

4) 13 статьяда:

а) 1 өлешнең икенче абзацында “Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына” сүзләрен “Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары Судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына” сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә “Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына” сүзләрен “Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары Судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына” сүзләренә алмаштырырга;

5) 14 статьяның 13 өлешендәге икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Гамәлгә куючыларның (уртак гамәлгә куючыларның) берсе Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары булган вакытлы матбугат басмасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең бәяләмәләрен һәм башка документларын бастырып чыгарудан баш тартырга хокуксыз.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 11 ноябре
№ 90-ТРЗ